СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

18 июнь, 1997 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 65 (8077) | Бәясе билгеләнгәнчә

## Район сулышы:
## хәбәрләр, вакыйгалар, фактлар

### «Уңыш - 97» пресс - үзәге хәбәр итә

Район хуҗалыкларында сабан культураларын тукландыру төгәлләнеп килә. Хәзерге вакытта шикәр чөгендерен шаровкалау, кукурузның рәт араларын эшкәртү кебек агрочаралар киң колач җәйде. 17 нче июньгә аларның беренчесе район буенча барлык мәйданнарның 88, икенчесе 68 процентында үткәрелде. «Үрнәк», «Комбайн», «Правда» ассоциацияләре, сөт - май комбинатының «Илюткино» ярдәмче хуҗалыгында шикәр чөгендеренең рәт араларын эшкәртү үтә акрын темп белән бара.

Шикәр чөгендерен сирәкләү эше дә чират көтми. Байтак хуҗалыклар аны зур оешканлык белән башлап җибәрсәләр дә, «Игенче», «Алга», «Комбайн», «40 лет Победы», «Үрнәк» хуҗалыкларында сирәкләнгән мәйданнар бик аз әле.

Терлек азыгы хәзерләү - көн кадагындагы мөһим бурычларның берсе бүген. «Родина», «Кондырча», «Заветы Ильича», «Татарстан» кебек хуҗалыкларда үләннәре теземнәргә салынган мәйданнар көннән - көн арта. Ә менә «Комбайн», «Төрнәс», «Игенче», «Алга», Кузнецов исемендәге хуҗалыкларда хезмәт начар оештырылу сәбәпле, бер ритмга кереп китә алмыйлар.

150 тонна. Бүгенге көнгә «Кондырча» КФХАсында шул кадәр печән хәзерләнеп, эскертләргә куелды. Бу - планлаштырылган күләмнең 20 проценты кадәр. «Заря»да печән запасы 70, Мичурин исемендәге КФХАда 75, «Рассвет»та 60 тонна тәшкил итә. Ә менә «Правда», Хафизов исемендәге, «Игенче», «Комбайн», «Таң», Кузнецов исемендәге, шикәр заводының «Восход», сөт - май комбинатының «Илюткино», РСУның «Мамык» ярдәмче хуҗалыкларында ул бер центнер да хәзерләнмәде әле.

## ТӨП БУРЫЧЛАР БИЛГЕЛӘНДЕ

16 нчы июньдә район хакимиятендә АПК предприятиеләре җитәкчеләре катнашында уздырылган киңәшмәдә кырчылык һәм терлекчелек белән бәйле күп мәсьәләләр каралды. Район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьевның проблемалы чыгышында районда азык хәзерләү дәрәҗәсенең түбән булуы борчу белән билгеләп үтелде. Күп хуҗалыкларда күпьеллык үләннәрне чабу, печән җыю соңга кала. «Алга», «Комбайн», «Татарстан», «Таң», «Илюткино», Кузнецов исемендәге, «Заря», «Чирмешән» КХАларында аны хәзерләүгә керешмәгәннәр дә әле. Шунда ук 1 нче июльдән соң люцернаны җәйге чәчүгә туфрак хәзерләү кирәклегенә дә басым ясалды.

Урып - җыю эшләренә аз вакыт калып бара. Шуңа да ындыр табакларында үлчәү хуҗалыкларын, орлык киптерү, чистарту җайланмаларын әзерләү, складларны чистарту, техниканы әзерләү хакында җитди сүз булды. Витаминлы үлән оны хәзерләү, кырларны химияләштерү, органика чыгару да көн тәртибендәге бурычлар. Татлы тамыр эшкәртү темпы да тизләтүне сорый. «Үрнәк», Муса Җәлил исемендәге, «Комбайн» хуҗалыклары аны читтән ярдәмсез очлый алмаслар ахры. Иптәш Терентьев соңгы яшеннәр уңаеннан хуҗалыкларда янгын сүндерү җайланмаларын җитәрлек күләмдә булдыруга да игътибар юнәлтте.

Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе начальнигы Р.М.Гыйбадуллин терлекчелектә хәлләрне җентекләп анализлап, быел уртак көч белән әйбәт кенә нәтиҗәләргә ирешелүен билгеләп үтте. Район сөт җитештерү буенча республикада беренче унлыкта бара. Әмма, диде оратор, тынычланырга ярамый. Июнь продуктлылыкны күтәрү өчен иң кулай ай. Малларны көтү, өстәмә ашату, концентратлар бирү, дөрес көн тәртибен саклау зарур. Соңгы көннәрдә сөтнең сыйфаты начараюы да борчу тудыра. мөгезле эре терлекнең баш санын арттыру, дуңгызчылыкта хәлләрне яхшырту буенча да конкрет бурычлар куелды. Киңәшмәдә ягулык, авыл эшчәннәренә хезмәт хакы бирү мәсьәләләре дә күтәрелде, халыкка бурычны бетерү өчен мөмкин булганның барысын да эшләргә кирәклеге ассызыкланды.

## ӨЙРӘНГӘННӘРЕ - ҮЗЛӘРЕ ӨЧЕН

Районда 1979 нчы елдан бирле эшләп килүче һәм төп максаты - авыл өчен кадрлар хәзерләү булган 99 нчы һөнәр училищесы курсантлары авылдагы мөһим кампанияләрнең берсеннән дә читтә калмыйлар. Хуҗалыклар моны үзләренә ярдәм буларак кабул итсәләр, без, училище педагоглары аны производство практикасы дип атыйбыз. Икенче төрле итеп әйткәндә, авылда, җирдә эшләү уку программаларына кертелгән.

Узган уку елында безнең училищеда 250 кеше укыды. Шуларның иң зур күпчелеге киң профильле тракторчы - машинистлар иде. Калганнары авыл хуҗалыгы өчен бухгалтерлар, пешекчеләр, санитар - ветеринарлар, шоферлар һәм икенче разрядлы слесарьлар. Быел гына да 50 кеше бухгалтерлык, 17 кеше пешекче, 13 - е санитар - ветеринар таныклыклары алдылар. Болардан тыш, 90лап шофер, 15 слесарь да хәзерләдек. 65 кеше киң профильле тракторчы - машинист белгечлегенә ия булды. Әйтергә кирәк, аларның күпчелеге эшкә дә урнашты инде.

Училищеда укуларын дәвам иттерүчеләр исә һәрвакыттагыча быел да язгы кыр эшләрендә авыл хуҗалыгы ассоциацияләрендә эшләделәр. Училище администрациясе тарафыннан аларның 12 се «Правда»га, 16сы «Сөлчә»гә җибәрелсә курсантларыбыз «Якты Күл», «Кондырча» хуҗалыкларында да эшләделәр әле тагын. Калган 86 курсантыбыз чакыруларны район ассоциацияләреннән үзләре үк алып килделәр. Шунысы куанычлы, курсантларыбыз авыл җирендә кичәне ачып, зур тырышлык куеп эшләделәр быел. Училище педагоглары тарафыннан оештырылган тикшерү - рейдлар, хуҗалыклар җитәкчеләре, белгечләр сүзләренә таянып әйтәм мин бу сүзләрне.

Болардан тыш, уку йорты хуҗалыкларга техника белән дә ярдәм итеп тора. Быел язгы чәчү вакытында безнең тракторларыбыз «Якты Күл», «Комбайн», Әлмәт, Муса Җәлил исемендәге ассоциацияләрендә эшләде.

Җәйге чорда да безнең курсантларыбыз авылдагы эшләрдән читтә калмаячаклар. Печән хәзерләү белән мәшгуль булачак алар, уракта комбайнчы ярдәмчеләре буларак эшләячәкләр. Ярдәмнәре авыл өчен булса, өйрәнгәннәре үзләренә булачак бит.

**П.ВАСТРУШКИН,**
**99 нчы ПУ директоры урынбасары.**

## Шәфкать ияләре бәйрәмендә



Инде 32 ел рәттән традицион рәвештә медицина хезмәткәрләре үзләренең профессиональ бәйрәмнәрен тантаналы төстә билгеләп үттеләр. Үткән җомгада шул уңайдан оештырылган чара да анда катнашучылар өчен истә калырлык һәм кызыклы үтте. Эчкерсез, җылы бәйрәм атмосферасы фойеда ук сизелә иде: үзләренең тормышын кызыклы сурәтләр белән чагылдырган кулдан чыгарылган махсус газета янынннан беркем дә битараф үтеп китә алмады. Ә залда чәчәкләрдән хуш исләр аңкып торды.

Район үзәк шифаханәсе баш табибы З.А.Шабаев кичәне ачып, коллегаларын сәламләде һәм олы бәйрәмнәре белән котлау сүзләрен җиткерде. Ул чыгышында районда сәламәтлек саклау системасының тоткан урыны, аның бүгенге хәле, халыкның сәламәтлек дәрәҗәсе һәм аны ныгытуда медицина хезмәткәрләренең роле турында сөйләде. Район хакимияте исеменнән котлауны район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев җиткерде һәм шунда ук район үзәк шифаханәсенең стоматология бүлеге мөдире Р.Ә.Мостафинны Октябрь район хакимияте Мактау грамотасы белән бүләкләде. З.А.Шабаев дәвалау - профилактика эшчәнлегендә яхшы хезмәт куйган В.Я.Имуковага, Р.М.Лисюковага, Л.А.Смеловага, Д.Ф.Шәяхмәтовага ТР Сәламәтлек саклау министрлыгыннан Мактау грамоталарын тапшырды һәм тагын бер төркем медикларга рәхмәт белдерде. Зәкәрия Абдуллович шунда ук якташларының тормышын саклап калу өчен 30 - 40 ел дәвамында бушлай кан биргән донорлар - Л.Н.Кобызева, А.В.Иванова, Л.Ф.Михейкина, Л.Н.Гордеева, А.М.Фәхретдиновага мактаулы донор таныклыклары тапшырды. Аннары район медицина хезмәткәрләре исеменә юлланган күпсанлы - күрше районнардагы коллегаларыннан, санэпидкүзәтү үзәгеннән, үзәк аптекадан, хәрби комиссариаттан һ.б. килгән котлау телеграммалары белән таныштырды.

Район үзәк шифаханәсе баш табибы урынбасары М.Р.Галимов район шәфкать туташлары һәм фельдшер - акушерлар конкурсларында җиңүчеләргә Мактау грамоталары тапшырды. Ә ТР һәм РФ атказанган табиблары республика сәламәтлек саклау системасы тарихы турында сөйли торган «Медицина Татарстана в лицах» исемле китапка лаек булдылар.

Кичәнең тантаналы өлешен медицина хезмәткәрләре көче белән әзерләнгән концерт алыштырды: сәхнә җыр, бию белән, ә зал алкышлар белән тулды. Медикларның шәфкатьле һәм әзерлекле булулары өстенә гаҗәеп талантка да ия булуларына ачык мисал иде бу.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

### Акционерлар игътибарына!

**1997 нче елның 27 нче июнендә 8 сәгатьтә «Сельхозтехника»ның кызыл почмагында «Октябрь «Сельхозтехникасы» АҖе акционерларының гомуми җыелышы була. Көн тәртибендә:**

**1. Санау комиссиясенең сан составын билгеләү һәм аның әгъзаларын сайлау.**

**2. Отчетларны, балансны, табыш һәм зыян счетларын раслау.**

**3. Дивидендлар турында карар кабул итү.**

**4. Директорлар советын сайлау.**

**5. Җәмгыятьнең ревизия комиссиясенең сан ягыннан составын (ревизорны) билгеләү һәм аның әгъзаларын сайлау.**

**6. Аудиторны раслау.**

**7. Ачык типтагы акционерлар җәмгыятенең яңа редакциядәге Уставын раслау.**

### Бүгенге санда:

Район сулышы: хәбәрләр, вакыйгалар, фактлар


Балалар туклануы - олылар проблемасы

Терлекчелек - удар фронт

Укучыларыбыз хатларын укыйбыз

## Урамнарыбыз алар исемен йөртә

### Димитров Георгий Михайлович (1881 - 1949).



Болгар һәм халыкара эшчеләр хәрәкәте эшлеклесе. Эшче гаиләсендә туган. 12 яшеннән хәреф җыючы өйрәнчек булып эшләгән. 1901 нче елда матбагачылар профсоюзы сәркатибе итеп сайланган. 1902 нче елда Болгар эшче социал - демократлар партиясенә кергән. 1909 нчы елда Болгар коммунистлар партиясе дип исемләнгән партия Үзәк комитеты әгъзасы итеп сайлана. 1905 - 1923 нче елларда гомуми профсоюз сәркатибе буларак пролетариатның зур күтәрелешләрен оештыруда катнаша. Күп тапкырлар эзәрлекләүләргә эләгә. 1923 нче елда антифашистик коралды восстаниегә җитәкчелек итә, ул бастырылгач чит илгә китәргә мәҗбүр була. Фашистлар власте тарафыннан читтән торып үлем җәзасына хөкем ителә.

Эмиграциядә Коминтерн башкарма комитетында эшли. 1933 нче елда Рейхстагка ут төртүдә провокацион гаепләнеп Берлинда кулга алына. Немец фашистлары тарафыннан оештырылган Лейпциг процессында Гитлер провокациясен фаш итә, пролетар интернационализм байрагын югары күтәрә, фашизмга җимергеч мораль политик удар ясый. Бөтен дөньяда киң протест хәрәкәте фашистлар судын Димитровны акларга мәҗбүр итә. Советлар Союзы Димитровка совет гражданлыгы бирә.

1935 - 43 елларда - Комминтерн башкарма комитеты Генеральный секретаре. 1937 - 45 елларда СССР Югары Советы депутаты. II нче Бөтендөнья сугышы елларында фашистлар режимын бәреп төшерүгә китергән Болгариянең Ватан фронтын оештыручы. 1945 елда иленә кайта. Болгария халык республикасы Министрлар Советы рәисе, Болгария коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының генеральный секретаре.

1949 нчы елда үлә. Болгариядә аның исеме белән яңа шәһәр Димитровград, предприятие, урамнар атала. Күрше Мәләкәс шәһәре шулай ук Димитровград дип үзгәртелә.

**Рубриканы И.САНДЛЕР алып бара.**

## Оныклар үсә, проблема - арта

Бүген яшь ата - аналар өчен иң зур проблема нинди? Нәрсә киеренгә түгел, кием - салым белән базар тулган. Нәрсә ашатырга - хикмәт шунда. Әни кеше баласын туклыклы күкрәк сөте белән туендыра алмаганда - бигрәк тә. Бу күренеш исә хәзер адым саен, һәм яшь гаилә өмет тулы күз карашын балалар сөт кухнясына төби...

- Бүген биредә көнгә 1200 - 1400 порция әзерләнә, шулай да, кызганычка каршы, 2 яшькә кадәрге балалар ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерә алмыйбыз, - ди район педиатры Наилә Хәмитовна Усманова. - Юкса, ул дәвалау көченә дә ия. Моннан тыш, балалар һәм инфекция бүлекләрендә ятучылар да туклануны бездән алалар. Әлегә шәһәрнең көньяк өлешендә балалар игътибарсыз калалар, алар тимер юл поликлиникасына беркетелгәннәр. Шартларыбыз мактанырлык түгел. Замана стандарты буенча сөт комбинатларында сөт катнашмалары әзерләү буенча махсус цехлар булырга тиеш, безгә исә тарату пункты функцияләре генә кала. Бүген исә кухня район үзәк шифаханәсе йортында кечкенә, тыгыз, яраклаштырылган бүлмәдә көн күрә. Анда шундый зур күләмдә эш башкара алуларына хәйран калырлык. Валентина Михайловна Хәйруллина кухня белән 15 ел җитәкчелек итә инде. Җаваплы, намуслы. Сөт катнашмалары ясау технологиясен нечкәлекләренә кадәр белә. Коллективы турында түбәндәгеләрне сөйли:

- Без биредә 7 хатын - кыз: 4 диетсестра һәм 3 санитарка 1,5 сменалап эшлибез. Кызлар булдыклылар, пөхтәләр. Иң күп эшләүчеләр - диетсестра Нина Владимировна Булатова һәм санитарка Елена Васильевна Белова - кирәк булганда 12шәр сәгать тә эшлиләр. Ә эш җиңел түгел: кайнап торган сөт тулы флягалар һәм кәстрүлләрне ташы әле. Бер - беребезгә тулысынча ышанабыз. Зәкәрия Абдуллович Шабаевның хуплавын да һәрчак тоеп торабыз.

Сөт елгасы кухняны «Рассвет» хуҗалыгы белән тыгыз бәйли: биредән һәр көнне 2 центнерга якын сөт озатыла. Продукция әүвәл кайнатыла, суытыла, аннан соң гына ул бокска тапшырыла. Биредә сөтнең бер өлеше таратырга әзерләнә, икенчесеннән кефир, творис яки эремчек ясала. Бокста чисталык искиткеч, ә суыткычта закваска саклана. Бу «гөмбәчекләрне» коры рәвештә Мәскәүдән яздырып алалар, биредә тергезәләр, үстерәләр, сәгать саен күзәтеп торалар: күгәрек утырмасын, ачылыгы кимемәсен... Гөмбәләр белән Валентина Михайловна бары үзе генә эшли, процедурага хирург операциягә әзерләнгән кебек җентекләп көйләнә. Валентина Михайловна тынгысыз хуҗабикә кебек мәшәкатьләре белән уртаклаша: менә бер суыткыч сафтан чыккан, тизрәк төзәтәсе иде. Әзер продукцияне 13 сәг.тән 16 сәг.кә кадәр тараталар. Инде әни кеше шешә артыннан 3 көн килми икән, икенче көнне аны исемлектән сызып ташлыйлар. Чиста якта суыту залы, эремчек цехы бар, стерилизатор чыгымчылап тора. Тыгызлык, әлбәттә, күзгә кереп тора. Урын иркен булса, тагы күпме сабый тәмле диетик ризык алыр иде. Күпме сүз булды, үз оныкларына ризык кирәккәндә шәһәр «аталары» күпме вәгъдәләр бирделәр. Оныклары үсә, проблема кала бирә. Хәтта район шифаханәсе янкормасын очлап чыгуы да бик авыр - район финанстистлары тарафыннан бюджет соңгы меңенә кадәр тикшерелгән. Ә бәлки спонсорлар табылыр? Әллә аларның да оныклары үскәнме?

**Т.НАЗАРОВА.**

## Мунча үзгәрде

Ике атнадан артык МПП коллективы шәһәр мунчасын ремонтлады. Бар хезмәткәрләр дә көчләрен, вакытларын кызганмыйча фидакарь хезмәт куйдылар. Мунчабыз кыска гына вакыт эчендә тулысынча үзгәрде дә куйды. Вестибюль яктырып, иркенәеп китте, чишенү урыны яңартылды. Биредәге чисталык һәм җыйнаклык клиентларда әйбәт тәэсир калдыралар, мунчада булырга өлгерүчеләр аннан канәгать калдылар.

Без ремонт бригадасына, бу эшне оештырган һәм ныклы контрольдә торткан МПП җитәкчелегенә бик рәхмәтлебез.

**Мунча коллективы, шулай ук НЕБАЙКИННАР, РАССОДИННАР, НИКОЛАЕВЛАР.**

## Бармагың белән пичәт куй әле!

Русия Президенты гражданнарның бармак эзләрен теркәү турындагы закон проектын хуплады. Бу хакта инде 4 ел элек сөйләшә башлаганнар иде. Әмма «кеше хокукын бозалар» дип тавыш күтәрүчеләр күп булу сәбәпле, эш тукталып торды. Ләкин тормыш «бара» бит, кеше үтерүләр ешая тора. Соңгы ике елда гына да (әле урыс - чечен сугышында һәлак булучыларны исәпкә алмыйча) Русиядә шәхесе ачыкланмаган мәетләр саны 35 меңгә җиткән, ә бармак эзләре беркайчан да алдамый, охшаш эзләр 7 миллион кешегә бер генә туры килсә, тулысынча тәңгәл килгәннәре дөньяда юк. Бармак эзләрен теркәү турындагы закон АКШ, Франция, Израиль һәм башка кайбер илләрдә күптән яши икән.

Шулай итеп, профессионаллар теле белән әйтсәк, «пианинода уйнарга» әзерләнегез, җәмәгать!

## Ялган аракыга урын бар

Суррогат аракыларны моңа кадәр кая куярга белмичә аптырыйлар иде. Хәзер шикле аракыны махсус складларга китереп тикшерү уздыралар. Әгәр суд аны конфискацияләү турында карар чыгарса, экспертиза нәтиҗәләренә карап продукция эшкәртелә яисә халыкка сатыла, яисә юкка чыгарыла. Андый суррогат аракыны «Татспиртпром», Ленин исемендәге фәнни - җитештерү предприятиесендә, серкә заводында, «Хитон», «Мелита» акционерлык җәмгыятьләрендә яңадан эшкәртәчәкләр.

# Сабантуйлар! Сабантуйлар!

## МЕҢ ЯШӘ, МӘЙДАН!

Сабантуй - якташларымның яраткан бәйрәмнәренең берсе. Шуңа да бу көнне авылдагы бер генә кеше дә мәйданга чыкмыйча калмый. Быел да шулай булды. Бәйрәмнең беренче өлешендә язгы кыр эшләренә йомгак ясалды. Аның нәтиҗәләре буенча, шулай ук хуҗалык производствосының башка тармакларындагы нәтиҗәле эшләүчеләргә бүләкләр дә тапшырылды. Аннан соң бәйгеләр башланды. Атлар узышты, хатын - кызлар исә көянтә - чиләк белән су ташыдылар. Гомумән, мәйдан көне буе гөрләде, ә теге яки бу бәйгедә катнашырга теләк белдерүчеләр күпме иде тагын. Факиһә Кәлимуллина белән Фәридә Мәсгутова иң җитез су ташучылар итеп танылсалар, колга башындагы әтәч Айдар Мифтаховка насыйп булды. Авыш колга буйлап иң җитез йөргән Илгиз Зариповка да бүләкнең иң зурысы - сарык тиде. Гер күтәрергә теләк белдерүчеләр дә байтак иде. Шулай да ассоциациябез рәисе Мансур Фәссаховтан да көчле беләклесе табылмады: герләрне кулында уйнатыпмы - уйнатты.

Билгеле инде, көрәшне дә һәркем зур кызыксыну белән карады. Юраганыбыз юш килде: берничә ел рәттән сабантуй батыры булган Дамир Фәтхетдинов быел да һичкемгә бил бирмәде. Икенче урынга Шамил Гатин чыкты. Ә менә Фаил Фәссахов быел бар кешене «аһ» иттерде: яңа гына мәктәп тәмамлаган бу егетебез олы - олы абыйларын бер - бер артлы аркаларына салып, көрәштә өченче урынны яулады.

Сабантуй көнне мәйданда җыр - музыка бер генә минутка да туктап тормады. Кибетләр сәүдә итте. Пешекчеләр Әминә Сәгыйтова, Рәкибә Ногъманова һәм Гөлсинә Нәбиуллина көне бу казаннар яныннан китмәделәр: ашыйсы - эчәсе килгән бер генә кешене дә кире бормадылар алар.

Гомумән, сабантуй гөрләде, халык рәхәтләнеп бәйрәм итте. Бәйрәмгә килгән кунагыбыз - «Росгосстрах» - Татарстан дәүләт страховой фирмасының Октябрь филиалы начальнигы А.И.Газизуллин да ошатып китте.

**С.ФӘТХЕТДИНОВА,**
**хәбәрче.**
**Яңа Әмзә авылы.**

## КИЕКЛЕДӘ МИЛЛИ БӘЙРӘМ

***Район сабан туеннан соң икенче көнне халыкның көтеп алган традицион бәйрәме авылларда гөрләп дәвам итте.***

«Киекле» КАсында сабан туе үзенчәлекле һәм матур үтә. Ул быел да гаҗәеп күңелле булды. Тирә - як авылларын гына түгел, район халкын да сыендыра торган күркәм Тигәнәш аланы булгангадыр, бәлки. Быел да ул үзенең түренә кунакларны күпләп җыйды. Классташлар, еракдагы туганнар, дуслар белән нәкъ шунда, сабан туенда күрешелә дә бит. Ә ана оешкан төстә, зур әзерлек белән килгән киекләр. Сәүдә латоклары гөрләп торды. Халык та ул якка тилмереп карап тормасын дип, ассоциация җитәкчелеге кайгыртучанлык күрсәтергә җай тапты: сабан туе алдыннан гына хезмәт хакларын таратты.

Уеннар, көрәшләр һәркайсы традицион тәртиптә барды. Атлар чабышында хуҗалыкның ат караучысы Әсфат Газизовның улы Әсфан беренчелекне яулады. Милли көрәш буенча олылар арасында Чаллы шәһәренең педколледжында белем алучы Ринат Могайнетдинов, ә яшүсмерләр арасында 9 нчы сыйныф укучысы Линар Гыйльметдиновка тиңнәр табылмады. Гер күтәрүдә кооператив члены Әнвәр Мортазин егәрлеген күрсәтте.

Сабан туе мәйданында авылның оста җырчылары һәм район мәдәният йорты коллективы осталарының чыгышлары яңгырап, күңелне күтәреп торды.

# ҖӘЙЛӘҮ ЧОРЫ - МУЛ ПРОДУКЦИЯ ЧОРЫ

## Продукцияне күбрәк - максат шундый

«Родина» КХАсы зооветбелгечләре өчен хәзер җәйге лагерьдан да җаваплырак эш участогы юктыр, мөгаен. Баштарак, савым терлекләре җәйге лагерьга күчерелгәч, алардан продукция алуны киметмәү максатында, ашату режимы һәм рационын даими күзәтеп тордылар. Рацион дигәннән, ул кышлату чорындагыдан бер дә аерылмады. Сусыл азыкны да, тупасын да җитәрлек итеп бирделәр малларга, катнаш азыгын да кызганмадылар. Аннан акрынлап, җәйге рационга күчтеләр. Салам яшел азык белән алыштырылды. Өстенә барда да сибәләр. Барданы эчерәләр дә. Ә менә һәр баш малга бирелә торган фуражны 1 килограммга киметтеләр. Маллар исә көне - төне көтүдә. Бары тик 3 тапкыр - саву, ашату өчен генә кайтарыла алар җәйләүгә.

- Күчеш чорын төгәлләдек инде,- ди хуҗалыкның баш зоотехнигы Н.Н.Кузнецов,- эшне бер җайга салгач, безнең тарафтан контроль генә таләп ителә.

Ә әлегә белгечләргә борчылыр урын юк. Җәйләү кадрлар белән тәэмин ителгән, көн тәртибе, ашату режимы төгәл үтәлә. Шуның нәтиҗәсе буларак, маллардан продукция алу да көннән - көн арта. Уңган савучылар Агрепина Илюшкина һәм Флера Фәйзуллина группаларында ул аеруча кискен үсеп китте: кызлар һәр сыердан көн саен 17 - 18 килограмм сөт савалар.

Якын арада бозауларга тиешле буаз таналар белән дә аерым проблема туганы юк. Ике группа маллар кышкы абзарларда калдырылган. Бирелә эшләүче терлекчеләр Гамбәр Миндубаева белән Людмила Васильева сыерларны бозаулаталар да, яшь малларны үзләре үк карыйлар да. Бозаулаган сыерларны саву да алар вазифасына керә. Ә моның катлаулылыгын үзе бу эш белән шөгыльләнгән кеше генә беләдер, мөгаен. Яшь малларны саварга да, шул режимга күндерергә дә кирәк бит: абзарда гына тотылмыйча, көне буе урман - болыннарда көтелә бит алар.

Гомумән, родиналылар җәйләү чорын уңышлы башладылар. Хәзер бөтен максат мул сөт җитештерү өчен җайлы булган һәр көнне рациональ файдаланып эшләүгә тупланган. Терлекчеләр, зооветбелгечләрнең үз дигәннәренә ирешәселәренә шик юк. Әнә, узган ел биредә һәр сыердан 3.199 килограмм сөт савылган булган. Продукциянең шактый өлеше җәйге чорда җитештерелгән. Быел исә җәй тагын да нәтиҗәлерәк эшләп, ел дәвамында ким дигәндә 3.500 килограмм сөт саву исәпләре аларның.

## Эш башында торса Дәүләтша...

Салдакай авылында дуңгызчылык тармагында эшнең көйләнүен Дәүләтша Мостафин белән бәйлиләр. Гомере буе терлекчелектә эшләгән, ферма мөдире дә булган тәҗрибәле белгеч, шул ук вакытта зур оештыру осталыгына да ия җитәкче товарлыклы - дуңгызчылык фермасына ун еллап элек мөдир булып килә. Ни хезмәт күрсәткечләре, ни тәртибе белән ялтырамаган коллективны беренче көннән үк кулына ала ул. Хезмәтне оештыру, көн тәртибенең үтәлеше, нәсел эше, малларны ашату кебек әһәмияткә ия булган факторларны да һәрьяклап үлчи, анализлый. Билгеле инде, икенче көнне үк яхшы нәтиҗә көтми ул. Әмма Дәүләтша Фәйзрахманович ышана: дуңгызчылыкта эшләр һичшиксез яхшырырга, алай гына да түгел, кискен алга китәргә тиеш. Мөдир ялгышмый: хезмәт нәтиҗәләре озак көттерми. Үрчем алу арта, аның сакланышы яхшыра, дәүләткә тапшырылган итнең шактый өлешен дуңгыз ите алып тора.

- Дәүләтша абый булганда, анда безнең кирәгебез юк,- диләр хуҗалык җитәкчеләре, белгечләре.

Хәзер эшләр гөрләп бара фермада. Узган ел да начар эшләмәде коллектив. Һәр 100 анадан 2325 баш дуңгыз баласы алынды. Дәүләткә итне дә күп итеп тапшырдылар. Быелгы күрсәткечләр дә сөенечле. «Родина» КФХАсы дәүләткә ит сатуның яртыеллык заданиесен районда беренчеләрдән булып үтәде. Барлык итнең 60 процентын дуңгыз ите алып торды. Биш айда алынган үрчем 1250 баш тәшкил итте. Бу да узган елның шул чорындагыдан шактый артык.

Билгеле инде, бу күрсәткечләр үзеннән үзе генә килми. Мөдир тарафыннан маллар асрауның һәр циклына ныклы контроль урнаштырылуы, хезмәтне оештыруның нәтиҗәле алымнарын куллану, терлекчеләрнең намус кушканча эшләүләреннән тора бар нәрсә. Малларны дөрес итеп, баланслап ашату да аз әһәмияткә ия түгел. Ә биредә дуңгызлар өч тапкыр ашатыла. Барлык азыкларның 60 проценты - концентрацияләнгән. Бар төр азык эшкәртелеп ашатыла. Әле менә җәйге рационга күчкәч тә, яшел азыкны «Волгарь» вaклагычы аркылы чыгарып ашатмаган көннәре юк. Боткалар да рационда аерым урын тота. Билгеле инде, дуңгызларның барысы өчен дә җәйге лагерьлар булса, нәтиҗә тагын да югарырак булыр иде, мөгаен. Ә әлегә хуҗалыктагы 1.400 баш дуңгызның 70се генә лагерьларда. Алары бүген - иртәгә балаларга тиешле маллар. Гомумән, «Родина»да үрчем алу һәм аның сакланышын тулысынча тәэмин итү өчен күрелә торган чаралар теләсә кайсы хуҗалыкка үрнәк итеп алырлык. Шуңа да бу турыда җентекләбрәк сөйләмәкче булабыз. Быел бу малларны ирле - хатынлы Николай һәм Марина Матросовлар карый. Гаилә подряды нигезендә эшлиләр алар. Хуҗалык администрациясе белән төзелгән ике яклы килешү нигезендә гаилә бер балалатуга һәр ана дуңгыздан 6,5 дуңгыз баласы алырга тиеш Шуннан артыгын алар үзләренә калдыра яисә югарырак бәя белән хуҗалыкка сата алалар. Ике як өчен дә бик отышлы алым бу! Инде соңгы елларда «Родина»да дуңгызчылык үсешендә алда телгә алынган бу фактор да аз әһәмияткә ия нәрсә түгел.

Гомумән, родиналылар дуңгыз итенең тиз өлгерешле булуыннан бик оста файдаланалар. Алда әйткәнебезчә һәм хуҗалык җитәкчелеге, авылдашлары раславынча эшнең башында тынгысыз кеше - Дәүләтша ага Мостафин тора.

**Р.ГИНЯЕВА.**



Саимә Ибәтуллина - «Кондырча» крестьян һәм фермер хуҗалыклары ассоциациясенең иң уңган савучыларының берсе. Терлекчелектә күптәннән эшли ул, ярышта һичкайчан артта калганы юк. Әле бу көннәрдә дә хуҗалыкта аңардан күп сөт савучы юк: уңган савучы бүген дә һәр сыердан 20,2 килограмм сөт сава. Бу - хуҗалык буенча иң зур күрсәткеч. Шуңа да быел район Сабан туе флагын күтәрү кебек җаваплы, шул ук вакытта почетлы миссиянең Саимәгә тапшырылуы бер дә очраклы булмады.

**Рәсемдә: С.ИБӘТУЛЛИНА. Н.АЗИЗОВ фотосы.**


*Рейд бригадасы хәбәр итә*

## ӘЛМӘТ ФЕРМАЛАРЫНДА ХУҖА БАРМЫ?

Җәй: эсселек 30 градуска җиткәндә, сөтнең сыйфатын саклау җиңел түгел. Шуңа да терлекчеләр һәм белгечләрнең санитар - гигиеник нормаларын үтәве зур игътибар сорый. Әмма соңгы ике атнада Әлмәт КХАннан китерелгән сөтнең ачылыгы югары булды. Мисал өчен, 6 июньдә «Норлат - Октябрь сөт - май комбинаты» АҖе хуҗалыкка ачылыгы 22 градус булган 2967 килограмм сөтне кире кайтарырга мәҗбүр иде. Мондый сөт кабул ителми, шулай ук термик эшкәртүгә дә җибәрелә алмый. Хуҗалыклар кассасыннан миллионлаган сумнар җилгә очты, йөзләгән кешенең хезмәте юкка чыкты. Хуҗасызлыкның сәбәбе нидә?

Хуҗалыкта җәйге лагерьлар өчәү, әмма аларның берсендә дә санитар - гигиена таләпләре үтәлми. Беренчедән, сөт җыю һәм аларны төп сөт блогына күчерү өчен флягалар җитешми. Сөт җиһазларын җыю һәм дезинфекцияләүдә кулланыла торган кальцийлы сода һәм хлорлы известьның беткәненә дә күптән инде. Ә бит бу чаралар сөт - май комбинатында дефицит түгел һәм аларны юнәтү дә проблема тудырмый. Безнең бригада саву аппаратларын да тикшерде. Нәтиҗәсе бөтен җирдә дә бер төрле иде: шланглар, коллекторлар һәм саву стаканнары шундый пычрак ки, хәтта сөтне дә көч - хәл белән генә үткәрәләр. Савучылар аны кайнар су белән ялтыратып юып куйсалар проблема хәл ителәсе дә бит... Әммa моның өчен элементар шартлар юк - савытлар пычрак идәндә юыла, махсус стеллажлар гына түгел, «ерш»лар да җитешми хәтта. Беренче лагерьда хәл тагын да начар - кайчак срогында су да китерелми. Хет саву аппаратыңны өенә алып кайтып чистарт. Иске Әлмәт лагерендагы саву мәйданчыгына керә торган җирдә шакшы су тулган тирән базны антисанитария «һәйкәле» дип атап булыр иде, мөгаен. Сыерлар җиленнәреннән пычракка батып йөриләр.

Җыелган барлык продукция туплана торган сөт блогы да чисталык һәм тәртиптән ялтырамый. Пычрак тездән биредә, сазлыкта кия торган итекләрсез суыткычларга якын барып булмый. Ике суыткычның берсе эшләми. Сөт суырту шлангларының торышы да яхшы түгел. Биредә булганда безнең үзебезгә үк аларны чистартырга да туры килде. Моның өчен биредә табылган тимер чыбык кисәге бик ярап куйды.



Болар өстенә Әлмәттә сөт лабораториясе дә эшләми. Шулай булгач сөтнең сыйфатын ничек тикшерәсе дә, моны кем башкарасы?

Рейд бригадасы члennарының үз - үзләренә һәм тикшерү вакытында биредә булган хуҗалыкның баш бухгалтеры Ш.Гатин һәм экономист Җ.Хәйруллинга биргән соңгы сораулары түбәндәге эчтәлектә иде: товарлыклы - сөтчелек фермаларында хуҗа бармы? Ә аңа җавап булырга тиеш.

**А.БЕЛЯКОВА,**
**авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сыйфат буенча дәүләт инспекторы.**

**Н.КУДРЯШОВА,**
**сөт - май комбинатының лаборатория начальнигы.**

**Т.КОЛПАКОВА,**
**сөт - май комбинатының санитария табибы.**

# Безгә язалар Безгә язалар

●Тормыш хәлләре

## Бар әле изге кешеләр

Үткән елда безнең гаилә кайгылы хәл кичерде: мин Мәскәүгә товарларга барып әҗәткә алган 5 млн. акчамны урлатып буш кул белән кайттым. Аяныч хәлне төзәтү максаты белән процентка бурыч алып янә Мәскәүгә киттем. Ләкин бу юлы да баруым уңышсыз килеп чыкты: мин чирләп шифаханәгә яттым. Шулай итеп бурычны үз вакытында түли алмадык: процентлар көннән - көн үсеп ул шактый зур суммага әверелде. Нәтиҗәдә тормыш алып бару өчен бер тиен акчабыз калмады, хәтта өйдәге сатарга яраклы әйберләр дә сатылып бетте. Бәхеткә каршы, бу авыр көннәрдә минем иң якын кешеләрем - әни Миннехания Нәбиулловна Ильмухина һәм энем Ринат ярдәмгә килделәр. Аларның миңа күрсәткән изгелекләре мәңге онытырлык түгел. Шул ук вакытта миңа бөтенләй ят кешеләр - норлатлыларның да булышлыклары аз булмады. Бу яхшы күңелле, шәфкатьле кешеләрнең исемнәрен газета битләрендә атау минем өчен зур бәхет. Рузия Сәфәргалиева, үзе ярдәмгә мохтаҗ кеше, Гөлүсә Усманова гаиләсе белән берлектә бүгенге көнгә кадәр безне ярдәмнәреннән ташламадылар. Факиһә апа Әхмәтшина ихлас күңелдән кайгыбызны үзенеке итеп кабул итте. Ул миңа гына түгел, башка бик күпләргә үзенең ярдәмен кызганмый. Зөлфия Минхәерова, үзе тормышында олы кайгы кичергән кеше, бер үзе ике бала тәрбияләп үстерә, шул ук вакытта миңа да матди һәм мораль ярдәме аз тимәде. Гөлнур Закирова, Фәнүзә Газизова, пенсионер Минсара апа Сафиуллина һәм аның кызы Сания Бикметова, Асия Фәхриева, Галия Мифтахетдинова - бу кешеләргә һәрбарчасына рәхмәтем чиксез минем. Алар ярдәмендә әкрен булса да, мин авыр хәлемнән чыгу ягына барам. Шул мәрхәмәтле кешеләрнең изгелеген мин һәрвакыт күңелемдә саклармын.

Лилия ГАЙНЕТДИНОВА.
Норлат шәһәре.

## Сабантуйда шахмат ярышы

1997 елның 7 июне, сабантуй көнне тиз шахмат уенын сөючеләр өчен дә истә калырлык булды. Уенда катнашырга теләк белдерүчеләр күп булса да, приз өчен көрәшне 12 шахматчы алып барды.

Финалда катнашучылар бер әйләнештә уйнадылар, һәр партиягә 5әр минут вакыт бирелде.

Вакыт тиз үтте, менә җиңүчеләр дә мәгълүм булды. Бәйрәм турнирында җиңүче исемен НУРБдан А.З.Гыйльманов яулады, икенче урында Р.М.Миннебаев (кирпеч заводы), өченче урында И.Д.Крылосов (тимер юл) булдылар.




Өчесенә дә истәлекле бүләкләр тапшырдылар.

**02 хәбәр итә**

## Тынгысыз ай булды бу

2 июньдә кич белән район үзәк шифаханәсенең кабул итү бүлеге шәфкать туташларына байтак кына көч түгәргә туры килде: сәгать ярым эчендә бирегә берничә юл - транспорт фаҗигаләре нәтиҗәсендә баш мие селкенеп, бите бәрелеп, баш сөяге - мие травмалары белән 2 хатын - кыз, Кондырча елгасында коенганда саксызлык күрсәткән бер ир - ат китерелде.

Июнь башында ук берничә янгын теркәлде: Колбай Мораса авылында ташландык мәктәп сараенда, нефтьчеләр урамындагы «Промтовар»лар кибетендә, Елаур һәм Чулпан авылларында торак йортларда. Ключи поселогы дуңгыз фермасы котельнясында мазутка ут капты. Бик ашыкканда да юл хәрәкәте кагыйдәләрен онытырга ярамый. Кызганычка каршы, Төрнәстән А.Христофоров бу хакыйкатьне истән чыгарган. 5 июньдә «Урал» мотоциклына утырып, юл хәрәкәте тизлеген арттырган һәм идарә итү сәләтен югалтып, К - 700 тракторына бәрелгән. Нәтиҗәдә ике кеше - 41 яшьлек П. һәм 39 яшьлек К. зыян күргәннәр.

Шул ук көнне тагы бер авария булды, бу юлы район үзәгендә, Советская урамында ике машина техник зыян кичерделәр.

Берничә шофер ГАИ хезмәткәрләре белән очрашудан зур гаҗәпләнү кичерделәр. Салган баштан руль артына утыручылар арасында А.Х.Хәйруллин, И.З.Хәмидуллин, Р.И.Әсәдуллин, И.Г.Хәйруллин, В.Н.Маринин да бар иде. Сүз уңаеннан, соңгысына дәрәҗәле генә - (834900 сум!) штраф түләргә туры киләчәк.

## Афәрин, Римма!

Фома урта мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы Римма Сәлахова сочинениеләр язу буенча республика конкурсында беренчелекне алды.

Сочинение Тукай шигыреннән алынган. «Рус белән гомер кичердек сайрашып. Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» дигән темага тәкъдим ителә. Конкурсны республика мәгариф министрлыгы үткәрә. Биредә барлыгы 32 район һәм 9 шәһәрдән унынчы, унберенче сыйныфта укучы 89 бала катнашкан. Шушы көннәрдә конкурс нәтиҗәләре билгеле булды: Римма Сәлахова районыбыз, мәктәбе данын күтәреп беренче урынны яулады. Аңа ТРсы мәгариф министрлыгының Мактау грамотасы һәм укытучыларына рәхмәт белдерелде.

Республиканың зур шәһәрләре мәктәпләре һәм гимназияләре арасында гади авыл мәктәбе укучысы Р.Сәләхованың иң әйбәт сочинение белән танылуы район өчен бик куанычлы хәл. Римманы котлауларга район мәгариф бүлеге коллективы да, без дә кушылабыз һәм киләчәктә дә уңышлар телибез.

## ЦИВИЛИЗАЦИЯ БӘЛАСЕ

Кемгә ничек, ә менә безгә, Киров урамында яшәүчеләргә, күптән көтелгән цивилизация үз проблемаларын гына китерде. Эш шунда: асфальт юлыбыз булганчы барлык көнкүреш чүп - чарын җыеп без юл янындагы тирән канауларга сала идек. Инде хәзер юл да бар, ә менә чүп - чар җыю өчен контейнер куярга уйлаучы юк. Безгә нәрсә эшләргә? Кая гына мөрәҗәгать итсәк тә безнең сүзебезгә колак салучы булмады. Бәлки сез булышырсыз?

**Киров урамында яшәүчеләр исеменнән Борзовлар.**

## Автобус йөртүчеләр игътибарына!

**Россия Федерациясе Президентының 1992 нче елның 7 нче июлендәге «Пассажирларны мәҗбүри шәхси страховать итү турында»гы (өстәмәләр белән), 1994 нче елның 6 нчы апрелендәге «Мәҗбүри страхование сферасында дәүләт политикасының төп юнәлешләре турында»гы карарларына туры китереп, шәһәрара маршрутларда автобуста пассажирлар күчерү, шул исәптән туристлар, экскурсантлар йөртү 1997 нче елның 1 нче июненнән страховой кампания белән килешү булган очракта гына лицензияләнә. Соңгысының бу төрдә мәҗбүри страхование үткәрүгә лицензиясе булуы да шарт. Шәһәрара маршрутларда пассажирлар, туристлар һәм экскурсантлар ташучы автобус шоферларының барлык пассажирлар турында мәгълүматлар күрсәтелгән страховой полислары булырга тиеш. Бу шарт коммерция нигезендә яки шәхси ихтыяҗдан чыгып автобуста пассажир күчерүләргә дә кагыла. Әлеге күчерүләргә страховой полис булмаган очракта җаваплы кешеләр административ җаваплылыкка тартылалар.**

Дәүләт автотранспорт инспекциясенең Кама аръягы бүлеге.

# Котлыйбыз!

*Киекле авылында яшәүче кадерле әниебез **Сәрия Исмәгыйль кызы Шәриповага** шушы көннәрдә 55 яшь тула. Аны юбилее белән котлыйбыз, озын гомер, ныклы сәламәтлек, бәхет һәм әтиебез белән тигез гомер итүләрен телибез.*

*Котлы булсын, әнкәй, туган көнең,*
*Күзләреңдә нурлар уйнасын.*
*Бүгенгедәй шат елмайсын йөзең,*
*Кайгы чаткыларын күрмәсен.*

***Изге теләкләр белән тормыш иптәшең, улың, кызың, киявең, оныкларың.***



# Белдерүләр

### Сатабыз

**«Москвич - 412» автомашинасы.** Гагарин ур., 5 - 19 (16 сәг.тән соң).

***

**Көнчыгыш микрорайонында төзелеш материаллары белән төзелеп бетмәгән агач йорт.**
Советская ур., 102 - 6, (19 сәг.тән соң).

***

**ВАЗ - 2106.** К.Маркс проспекты, 5 - 8.

***

**ВАЗ - 21080, 1996 нчы елның маенда чыгарылган.** Тел.: 5 - 22 - 97.

***

**Ашыгыч рәвештә 1993 нче елгы ВАЗ - 21093, 25,5 млн. сум.** Тел.: 2 - 15 - 59.

***

**Йорт, 1995 нче елгы ВАЗ - 21061, ВАЗ - 2101.** Карбышев ур., 8.

***

**1994 нче елгы «Таврия».** Тел.: 5 - 27 - 95.

***

**Циолковский урамындагы 9 нчы йортта 12 нче номерлы өч бүлмәле фатир.**

***

**1994 нче елгы ВАЗ - 21061.** Козлов ур., 16 - 16.

***

**Югары Норлатта йорт.** Тел.: 2 - 25 - 47.

***

**Ашыгыч рәвештә Әфган поселогында фундаменты белән участок.** Тел.: 5 - 26 - 08, 16 сәг.тән соң.

***

**Яхшы хәлдәге ВАЗ - 2101.** Тел.: 2 - 17 - 76, адрес: Молодежная ур., 13 - 6.

***

**1984 нче елгы ВАЗ - 2105.** Тел.: 2 - 10 - 17.

***

**1995 нче елгы «Москвич» ИЖ - 2715, Иж - Юпитер мотоциклы, кыйммәт түгел.** Тел.: 4 - 13 - 55, Мамык авылында Прокудинга мөрәҗәгать итәргә.

***

**1994 нче елгы ГАЗ - 31029 «Волга» машинасы, СПТУ бистәсендә 8 сутый участогы белән гараж.** Тел.: 2 - 10 - 60.

***

**Фундамент блоклары.** Тел.: 5 - 13 - 55, 16 сәг.тән соң.

### Алыштырабыз

**Ике бүлмәле фатирны өстәмә түләп өч бүлмәлегә.** Арадашчы тел.: 2 - 19 - 54.

***

**Өч бүлмәле фатир бер һәм ике бүлмәлеләргә. Бишегә белән ИЖ - Планета - 5" мотоциклы, 1980 нче елгы ВАЗ - 2103 сатыла.** Тел.: 5 - 18 - 17.

***

**Шәхси йорт бер бүлмәле фатирга.** Лермонтов ур., 41 йортка мөрәҗәгать итәргә.


### Идел Буе региональ наркология үзәге

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне пәнҗешәмбе 20 июньдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


Район хакимиятенең финанс бүлеге коллективы шофер **Әлфис Әмир улы Гыйләҗевның** вакытсыз үлүе сәбәпле тирән кайгы кичерә һәм мәрхүмнең туганнарының, якыннарының авыр хәсрәтен уртаклаша.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә. Заказ N 7198